ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Соболевский авыл җирлегенең Чулпаниха торак пунктында
2026 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

2025 елның 20 ноябре №6

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Чулпаниха торак пунктында гражданнар җыены
КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Чулпаниха торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түбәндәге категория гражданнардан тыш, 2026 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертергә:
а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;
б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.
Аерым категория гражданнар өчен:
а) 1нче төркем инвалидлар,
б) күп балалы гаиләләр,
в) көндезге уку йортлары студентлары,
түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
Чулпаниха торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Соболевский авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
ТР Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н.Майорова